РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ ЕВЛАШТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422075,Республика Татарстан, Сабинский район, с.Евлаштау, ул. Ш.Бариева, д.23
тел. (84362) 46-8-49

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯВЛАШТАУ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422075, Татарстан Республикасы, Саба районы, Явлаштау авылы, Ш.Бариев урамы, 23 йорт
тел. (84362) 46-8-49

e-mail: Evlash.Sab@tatar.ru


РЕШЕНИЕ
03.06.2021

КАРАР
№13

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советының 25.03.2013 ел, № 13 карары белән расланган Явлаштау авыл җирлегендә гражданнар тарафыннан хосусыйлаштырылган торак биналарны муниципаль милеккә тапшыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына ана (гаилә) капиталы средстволарын куллануга бәйле мәсьәләләр буенча үзгәрешләр кертү турында» гы Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» гы № 35-ФЗ Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советы

Карар кылды:

1. Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советының 25.03.2013 ел, № 13 «Гражданнар тарафыннан хосусыйлаштырылган торак биналарны Явлаштау авылҗирлегенә муниципаль милеккә тапшыру тәртибе турында" гы карары белән расланган Явлаштау авылҗирлеге Советы тарафыннан хосусыйлаштырылган торак биналарны гражданнар тарафыннан муниципаль милеккә тапшыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. хосусыйлаштырылган торак урыннарны Явлаштау авыл җирлеге муниципаль милкенә тапшырырга теләгән гражданнар, Явлаштау авыл җирлеге башкарма комитетына торак урынының барлык милекчеләре тарафыннан имзаланган, гражданның шәхесен таныклаучы документның төп нөсхәсен күрсәтеп, Явлаштау авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе исеменә гариза тапшыралар. Гаризага муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты белән билгеләнә торган документлар теркәлә.»

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/

eviashtay адресы буенча, җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Нуриев